КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 октябрь г.Казань № 946

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тереклек эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2010 ел, 1 апрель, 216 нчы карары белән расланган «Тереклек эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тереклек эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2010 ел, 1 апрель, 216 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 3 июль, 471 нче, 2017 ел, 22 декабрь, 1027 нче һәм 2018 ел, 27 июнь, 525 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Тереклек эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына, 4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.6 – 4.10 пунктларны өстәп, үзгәреш кертергә:

«4.6. Мәнфәгатьләр каршылыгы дигәндә Учреждение хезмәткәренең шәхси мәнфәгате (турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган) аның тарафыннан хезмәт йөкләмәләрен тиешенчә үтәүгә тәэсир иткән яки тәэсир итәргә мөмкин булган һәм Учреждение хезмәткәренең шәхси мәнфәгате һәм ул хезмәткәре булган Учреждение хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында каршылыклар килеп чыккан яки

килеп чыгарга мөмкин булган, Учреждение мөлкәтенә һәм (яки) эшлекле репутациясенә зыян китерергә сәләтле хәл күздә тотыла.

4.7. Учреждение хезмәткәренең шәхси мәнфәгате аның тарафыннан хезмәт йөкләмәләрен тиешенчә үтәүгә тәэсир иткән яки тәэсир итәргә мөмкин булган дигәндә хезмәт йөкләмәләрен үтәү белән бәйле Учреждение хезмәткәре тарафыннан акча, кыйммәтле әйберләр, бүтән мөлкәт, шул исәптән мөлкәткә хокуклар рәвешендә керемнәр, мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр, хезмәткәр һәм (яки) аның белән якын туганлыкта яки үги туганлыкта торучы затлар (әти-әнисе, ире яки хатыны, балалары, ир туганнары, кыз туганнары, шулай ук ире яки хатынының ир туганнары, кыз туганнары, әти-әнисе, балалары һәм балаларының ире яки хатыны), хезмәткәр һәм (яки) аның белән якын туганлыкта яки үги туганлыкта торучы затлар мөлкәти, корпоратив яки бүтән якны мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән гражданнар яки оешмалар тарафыннан башкарылган эшләр яки ниндидер файдалар (өстенлекләр) нәтиҗәләре күздә тотыла.

4.8. Директор вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килү турында Гамәлгә куючыга хәбәр итәргә тиеш.

4.9. Учреждение хезмәткәре вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси мәнфәгатьләр барлыкка килү турында Директорга хәбәр итәргә тиеш.

4.10. Директорга хәбәр итү тәртибен, хәбәрнамәләрдәге мәгълүматлар исемлеген, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыруны һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибен Директор билгели.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин